КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 сентябрь г.Казань № 991

Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

2023 елга дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны бер көнгә бер белем алучыга – 58,94 сум, 2024 елга – 61,30 сум, 2025 елга – 63,75 сум күләмендә;

2023 елга башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен – 58,94 сум, 2024 елга – 61,30 сум, 2025 елга – 63,75 сум күләмендә.

2. Җирле үзидарә органнарына муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны бер көнгә бер белем алучыга билгеләү буенча шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирә торган мәгариф программалары

буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында» 2021 ел, 6 сентябрь, 826 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин